

Үткән атнада Мордовиядә уникаль иҗтимагый институт – тобәк Главасы каршында Гаилә советынын беренче утырышы vтте.
Мордовиядә яна иҗтимагый инициатива тормышка ашырылды – Глава каршында Гаилә советы тозелде. Анын эш форматы безнен тобәк очен генә тvгел, тулаем ил очен дә уникаль. Бу институт гаилә мәсьәләләрен хәл итv очен генә тvгел, ә бу темага рәсми булмаган якын килv очен тозелгән.
Гаилә советы эше 30 сентябрьдә, Мордовиядә быел беренче тапкыр билгеләп vтелә торган кvп балалы Гаилә конендә башланды.       Дәvләт Советынын «Гаилә» юнәлеше буенча комиссиясен житәкләvче Мордовия Главасы Артём Здунов билгеләп vткәнчә, Россия Президенты халыкны саклау олкәсендәге мәсьәләләрне һәм бурычларны тогәл билгеләде. Аларга ирешv һәм жәмгыятьтә хәзер актив булган тискәре тенденцияләрне булдырмау очен кvп юнәлешләр буенча эшләргә туры киләчәк.
Мордовия Главасы тvбәндәге статистиканы ишеттерде: республиканын 207 меннән артык гаиләсеннән балалы парлар – 73 мен, 65 мене - баласыз парлар. Жавап таләп итә торган топ сорау: ни очен бу гаиләләрдә балалар юк?
Хәзер тобәктә балалы гаиләләргә ярдәм итvнен 40тан артык чарасы гамәлдә. Предприятиеләрдә һәм оешмаларда гаиләләргә корпоратив ярдәм кvрсәтv буенча зур эш алып барыла. Алар турында һәрьяклап хәбәрдар булу, шулай ук аларнын нәтижәлелеге турында кире элемтә актуаль булып кала. Бу бурыч, шул исәптән, Совет әгъзалары алдында да тора. Нәкъ менә шуна кvрә Совет составы кvпкырлы. Ана 50 гаилә пары – кvп балалы һәм яшь гаиләләр, СВОда катнашучыларнын гаиләләре, гаилә конкурсларында жинvчеләр һәм федераль грантлар алучылар, гаилә бизнесы һәм эре предприятиеләр, кvп балалы хезмәт династияләре, иҗтимагый һәм дини оешмалар, мәгариф һәм сәламәтлек саклау олкәсе учреждениеләре вәкилләре керде. Совет составындагы гаиләләрнен 82% ы - оч һәм аннан да кvбрәк балалы гаиләләр. Советны Мордовия Главасы Артём Здунов житәкләде, ә урынбасарларынын берсе Россия Федерациясенен «Героиня-Ана» исеменә лаек булган 10 бала анасы Ольга Исайкина һәм парламент вице-спикеры Наталья Долматова булды.
Кvп балалы әти, РМ Главасы секретариаты житәкчесе, Гаилә советы секретаре Михаил Никишин әлеге структуранын топ максатларын билгеләде: демографик инициативалар, шул исәптән гаиләләргә ярдәм итvнен «халык» һәм закон чыгару, актуаль чараларын эшләv, шулай ук теләсә нинди тобәк проектларында һәм дәvләт программаларында, предприятиеләр эшендә Гаилә vзәклеге принцибы vтәлешенә жәмәгатьчелек контролен тәэмин итv. Әмма советнын рәсми булмаган эшендә ин моһиме – гаилә мәсьәләләренен кин даирәсенә эләкми торган хәлләр буенча карарлар эзләv. Бу гаиләләрдә ир белән хатын арасындагы монәсәбәтләр, гаилә психологлары эше, милләтара һәм динара монәсәбәтләрнен vзенчәлеге, тулы булмаган гаиләләрдә балалар тәрбияләv һәм ата-аналарнын бу бурычлардан читләшvе. Шунысы моһим, Совет әгъзалары тарафыннан мондый нигез моментларын эшләv федераль дәрәжә очен тәжрибә дә булачак.
Саранск һәм Мордва митрополиты Зиновий балаларны тәрбияләvдә һәм гаилә

кыйммәтләрен ныгытуда рухи нигезләрнең, топ яхшылыкларның мөһимлеген ассызыклады: «Гаилә – ул тере организм, иң мөһиме һәм беренчел. Гаилә шәхесне үстерә».
Мордовиядә бала табуда ярдәм итү системасының заманча мөмкинлекләре, сабыйлар үлемен киметү буенча эш һәм 2026 елда Перинаталь үзәкне модернизацияләү буенча планнар турында Гаилә советында «Мордовия республика үзәк клиник хастаханә»се, күп балалы әти, табибларның хезмәт династиясе әгъзасы Сергей Ладяев сөйләде.
Совет әгъзасы, СВО ветераны Дмитрий Волков күп балалы гаилә булу тәҗрибәсе белән уртаклашты. Яраланганнан соң өйгә кайткач һәм тернәкләнү узгач, алар хатыны белән өченче бала туу турында уйлана башлыйлар. «Ходай бирде безгә аны! Ә күптән түгел улым братик сорады – бу хакта гаиләбез советында фикер алыштык», - диде күп балалы әти.

«Сез безнең өчен - җәмәгатьчелек фикере лидеры. Демографик тема – бүгенге чынбарлыкта иң катлаулы тема, һәм безгә аны хәл итәргә туры киләчәк!» - дип хуплады Мордовия Главасы.
«Кантриум» технологик стартапына нигез салучы Мария Соколова бо-лай дип сөйләде (аның күп балалы гаиләсе өч ата-ана гаилә форумында, шул исәптән «Ялгат» форумында катнашты): «Бу безне әти-әни буларак активлаштырды. Сынап карарга гына кирәк – бу иң яхшы мотивация! Үз балаларыбыз өчен топ иҗатчылар икәнебезне без үзебез анларга тиеш!»
Актив иҗтимагый позициянең тагын бер мисалы - «Гаилә территориясе» АНО генераль директоры, күп балалы әни Екатерина Деринская чыгышында: «Ана булуга ярдәм итү - минем миссиям!- диде ул. - Президент грантлары фонды ярдәмендә без Саранск бала тудыру йорты инфраструктурасын модернизацияләү буенча дүрт проект-ны гамәлгә ашырдык.»
Гаилә советының беренче утырышы азагында Артём Здунов әлеге темага игътибарлары һәм шәхсән катнашулары өчен барлык әгъзаларына рәхмәт белдерде: «Сейчас это острый вопрос: как вернуть моду на семейные ценности, на большую многодетную семью, на семейно ориентированные отношения мужчины и женщины. У Семейного совета очень важная идеологическая работа. Ключевые решения мы традиционно принимаем на семейном совете, а мы все в нашей республике – большая дружная семья, поэтому давайте вместе подумаем, какие нам предпринять эксклюзивные шаги, чтобы кардинально поменять эту ситуацию!»

**Наилә НАСЫРОВА**